**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**21 май 2020 ел** **№280**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының 2014 елның 8 апрелендәге 301 номерлы «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 декабрендәге 455-ФЗ номерлы Федераль законның 27 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы, КАРАР ИТТЕ:

1. Муниципаль район Советының 2014 елның 8 апрелендәге 301 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә җәмәгатъ тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә (алга таба-нигезләмә) үзгәрешләр кертергә, Нигезләмәнең 5 статьясындагы 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үткәрү вакыты һәм урыны күрсәтелгән җәмәгатъ тыңлауларын үткәрү турында карар һәм җәмәгатъ тыңлауларына чыгарылучы тиешле муниципаль норматив хокукый акт проекты  Нурлат муниципаль районы җирле үзидарә органы тарафыннан расланган массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми рәвештә  яисә Нурлат муниципаль районы территориясендә таратыла торган башка басма массакүләм мәгълүмат чараларында,  гамәлдәге законнарда әгәр башка срок каралмаган булса,  җәмәгатъ тыңлаулары уздырылган көнгә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча басылып чыгарга тиеш.».

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының Законлылык һәм хокук тәртибен саклау буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы рәисе А.С. Әхмәтшин